| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2018 Казан ш. № 10-16/кс

Техник (химик чистартылган) суга, эчәргә яраклы суны транспортировкалауга, агып төшә торган суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар өчен техник (химик чистартылган) суга, эчәргә яраклы суны транспортировкалауга, агып төшә торган суларны транспортировкалауга тарифларны әлеге карарга кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 сентябрендәге 10-16/кс
номерлы карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар өчен техник (химик чистартылган) суга, эчәргә яраклы суны транспортировкалауга, агып төшә торган суларны транспортировкалауга тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Техник (химик чистартылган) суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Эчәргә яраклы суны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Агып төшә торган суларны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | карар үз көченә кергән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | карар үз көченә кергән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| 1 | «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | |
| 1.1 | «М-14 микрорайоны» торак комплексы һәм М.Гафури урамындагы 1, 2 , 4, 5 нче торак йортлар кулланучылары | | | |
| 1.1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән) | | 17,85 | 22,70 |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | |
| 2. | «Түбән Кама Нефтехим» гавами акционер җәмгыяте | | | |
| 2.1 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән) | 44,15 | | |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге